Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының
“Гомуми төрдәге № 31“Чишмә” балалар бакчасы” муниципаль
мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениесе”

# Зурлар төркемендә озакка сузылган проект эшчәнлеге

# «Икмәк – яшәү терәге»

Әзерләде югары
квалификация
категорияле тәрбияче
Вафина Ф. В.

Зеленодол шәһәре, 2013 ел

- **Проектның эшчәнлеге:** информацияле тикшеренү, танып белү, иҗади эзләнү.
- **Предметлы – эчтәлекле өлкәләре:** танып белүне үстерү, экология, хезмәт.
- **Катнашучылар саны:** төркем белән.
- **Үткәрү вакыты** - 2 ай.
- **Характер буенча контакт (урап алу дәрәҗәсе):** белем бирү учреждениесе рамкаларында.
- **Проектны оештыруның төп формасы:** фәнни – тикшеренү эшчәнлеге, предметлы үстерү тирәлеген җиһазландыру, әти-әниләр белән эш.

# Проблема:

Балага икмәк игү процессы турындаербөтен күзаллауны эзләп табарга ничек булышырга, бу процесста зурларның хезмәт эшчәнлегенең мөһимлеген аңлап төшенеп җитәргә, икмәк - ул бик күп кешеләрнең хезмәт нәтиҗәсе булуы турында балаларны мәҗбүр итмичә нәтиҗә чыгарырга этәрү.

**Максат:** Мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркеме балаларында танып белү, тикшеренү процессында һәм иҗади-сәнгать эшчәнлегендә фәнни – экологик белемнәрен формалаштыру.

# Бурычлар:

- Ипинең ничек итеп кешенең өстәленә килүе, икмәкне үстерү процессы турында балаларда беренчел күзаллау бирү;
- Мәктәпкәчә яшьтәге балага аңларлык итеп бөртекле үсемлекләрне үстерү үзенчәлекләре турында элементар экологик белемнәрен формалаштыру;
- Төрле шартларда һәм туфракта орлыкларның үсүен күзәтү осталыгын һәм күнекмәләрен формалаштыру;
- Хезмәт нәтиҗәсен бәяләү өчен аның мөһимлегенә һәм кыйммәтенә, икмәк һәм иген игүчеләр турында үзләренең уй-фикерләренә нигезләнеп сөйләм-исбатлау осталыкларын куллануны формалаштыру;
- Икмәк үстерүгә бәйле булган һөнәр ияләренә, табигать дөньясына танып белү кызыксынучанлыгын үстерү;
- Эштә ашамлыкларны (он, тозлы камыр, токмач әйберләре) кулланып иҗади сәләтләрен үстерү;
- Икмәккә, бөтен бер табигатькә карата эмоциональ – уңай, сакчыл, кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү.

# Проект идеясе:

Балаларга икмәкнең табынга нинди урау юллар белән килүен һәм аның һәркемгә кирәклеген аңлату.

# Проектта катнашучылар:

МБДОУ №31 «Чишмә» зурлар төркеме балалары.



# Көтелгән нәтиҗәләр:

- Балаларда танып белү активлыгын, иҗади сәләтләрен үстерү;
- Сүзлек запасын активлаштыру һәм тулыландыру, сөйләм – исбатлауны үзләштерү, икмәк һәм бөртек производствосы белән бәйле булган һәр төр хезмәт эшчәнлегенә бәясен дөрес нигезли белү;
- Хәлдән килгәнчә булышырга омтылыш, зурлар хезмәтенә ныклы кызыксынучанлык булдыру;
- Хезмәтнең төрле төрләре арасындагы бәйләнешне билгели белү;
- Экспериментлар алымнарын һәм ысулларын үзләштерү;
- Кешенең хуҗалык эшчәнлеге турында элементар күзаллауны устерү, ипине бәрәкәтле куллануны тәрбияләү;
- Балаларны бөртекле үсемлекләрне үстерүнең үзенчәлекләре белән таныштыру, бөртекле культураларның аермасы һәм охшаш билгеләрен табу, ипигә карата сакчыл караш тәрбияләү;
- Элементар тәҗрибә эшен үткәрергә өйрәтү (төрле шартларда орлыклар үсүе) төрле инструментлар һәм эш кораллары белән эшләү алымнарын үзләштерү;
- Балаларның иҗатта үз-үзләрен күрсәтүе.

# Проект барышы

**1 ЭТАП –** әзерлек (проектны эшкәртү)

2 атна.

## *Педагоглар эшчәнлеге:*

- проблеманы билгеләү, максат һәм бурычлар;
- мероприятиенең перспектив планын төзү;
- эшләү методларын билгеләү;
- методик, фәнни-популяр һәм матур әдәбият, иллюстрацияле материаллар сайлау;
- балаларның иҗади һәм продуктивлык эшчәнлеге өчен материаллар сайлау;
- театр һәм уен эшчәнлеге өчен атрибуттлар, уенчыклар, материаллар сайлау;

## *Уртак эшчәнлек:*

- балаларның аңына аңлаешлы һәм аларның тәҗрибәләренә якын булган проблемалы ситуациягә кертү;
- проектның тематикасына карата тотрыклы кызыксынучанлык формалаштыру;
- актуаль һәм көч җитәрлек бурычлар тезмәсен билгеләү;

## **2 ЭТАП –** тикшеренү (проектны үтәү) 4 атна.

- Белемне, осталыкны, сәләтне формалаштыру, аерым алганда олылар ярдәме белән һәм мөстәкыйль рәвештә проблеманы чишү.

## **3 этап –** йомгаклау(гомумиләштерү) 2 атна:

- куелган максатка ирешү һәм алынган нәтиҗәне анализлау;
- эш нәтиҗәләрен гомумиләштерү, йомгаклау;
- проект буенча эш процессында җыелган материалларны гомумиләштерү, төркемдә ипинең мини-музеен ачу;
- йомгаклау этабы: ачык чара “Башакның сәяхәте”.

# “Макаронлы портретлар”








# “Мин пешерәм, пешерәм!”













# Дидактик уен: “Ал һәм әйт”



# Дидактик уен:
# “Кыр эшләренең төрләре”



# Дидактик уен: “Тәртип буенча тезеп чык һәм сөйлә”








# “Ни өчен бөртекне җиргә чәчәләр?”


















ИКМӘК-ЯШӘҮ ТЕРӘГЕ

# Игенче хезмәтенә миниатюр а

